КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1075

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән расланган акчалары шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 648 нче; 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1435 нче; 2023 ел, 21 март, 309 нчы; 2023 ел, 27 апрель, 534 нче; 2023 ел, 26 июль, 890 нчы; 2023 ел, 15 ноябрь, 1481 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1574 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1737 нче; 2024 ел, 27 август, 700 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган акчалары шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 33 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«33. Күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтенә капиталь ремонт ясау эшләрен башкаруга төзелеш контролен гамәлгә ашырган өчен алынган керемнәр.».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин